КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 декабрь г.Казань № 1209

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, хәрби припасларның, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары турында» 1995 ел, 5 август, 545 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коралның, хәрби припасларның, коралга патроннарның, шартлаткыч җайланмаларның һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары турында» 1995 ел, 5 август, 545 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1995 ел, 15 ноябрь, 832 нче; 2002 ел, 25 октябрь, 625 нче; 2003 ел, 4 апрель, 179 нчы; 2004 ел, 17 май, 239 нчы; 2008 ел, 2 октябрь, 724 нче; 2010 ел, 17 август, 661 нче; 2012 ел, 25 сентябрь, 800 нче; 2016 ел, 31 март, 192 нче һәм 2016 ел, 13 сентябрь, 638 нче, 2019 ел, 1 апрель, 255 нче, 2020 ел, 21 август, 717 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Карарга теркәлгән Тиешле рөхсәтсез сакланган яисә Татарстан Республикасы территориясендә табылган кораллар, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрне үз иреге белән тапшырган гражданнарга акчалата бүләк бирү эшен оештыру турында нигезләмәне расларга.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетын үз ирекләре белән тапшырылган кораллар, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләр өчен акчалата бүләк бирүгә бәйле чыгымнарга юнәлдерелә торган акчаларны төп бүлүче итеп билгеләргә.»;

Законсыз саклаңган яки табылган корал, сугыш кирәк-яраклары, коралга патроннар, шартлаткыч җайланмалар һәм шартлаткыч матдәләрне кабул итү эшен оештыру турындагы нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин